ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

# ПРИКАЗ

19.04.2018 № 12-07/59

Казан ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе
эмблемасын раслау турында

“Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы турында” 10 гыйнвар, 2002 ел, № УП-21 Татарстан Республикасы Президенты Указына туры китереп, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми символларыннан файдалануны системалаштыру максатыннан чыгып, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эмблемасын гамәлгә куярга.

2. Түбәндәгеләрне расларга (кушымта итеп бирелә):

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасы турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасы тасвирламасын;

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасы рәсемен.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлегенә (Василина Л.П.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе структур подразделениеләре һәм территориаль органнары җитәкчеләре игътибарына җиткерергә.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Җ.Й.Әхмәтханов**

Административ һәм суд практикасы
бүлеге
начальнигы урынбасары ________________________________/И.И. Җамалетдинов/_________

Кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы
көрәш бүлеге начальнигы ____________________________/Л.П. Василина/____________

Татарстан
Республикасы Дәүләт алкоголь
инспекциясенең
_19.04. 2018 ел
№ 12-07/59 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасы турында нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр:**

1.1 Эмблема – оешманың төп идеясен гәүдәләндерергә тиешле шартлы яки символик сурәт. Дәүләт алкоголь инспекциясенең эмблемасы “Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре” 05 август, 2005 ел, №391 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эш итүче башкарма хакимият органы – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми символы булып тора.

1.2 Эмблема Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең функцияләрен нәтиҗәле башкару һәм дәүләт хезмәтләрен сыйфатлы рәвештә күрсәтү символы булып тора.

1.3 Эмблема Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы тарафыннан карап тикшерелергә һәм Татарстан Республикасы Геральдика реестрына кертелергә тиеш.

**1.4** Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эмблемага хокукы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә саклана.

**2. Куллану өлкәсе:**

2.1. Эмблема Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясен индивидуальләштерү өчен кулланыла, һәм ул түбәндәгечә кулланылырга мөмкин:

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе бүлекләрендә;
- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең интернеттагы рәсми сайтында;
- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан эшләнелә торган мәгълүмати басмаларда; кино-видео һәм фотоматериалларда; семинарлар, киңәшмәләрнең презентация материалларында һәм экспозицияләрендә; дегустацияләр үткәргәндә, программаларда;
- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе ярышларында катнашучыларның спорт киемендә.

2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасын куллануның башка очраклары Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчелеге тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең
19.04.2018 2018 ел,
№ 12-07/59 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасының тасвирламасы**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасы яшел җирлектә ике әйләнәдән – эчке һәм тышкы әйләнәләреннән торган, тышкысы дүрт түгәрәк манарадан торган (барысы да – алтынсу төстә); тар нурлары өслегендә нурның өчтән ике өлешен алып торган кызыл төстәге ике полосалы дүрт почмаклы алтын йолдыз; алтынсу төстәге ике сызык белән читләтеп, яклары чыгып торган арасы яшел сызыклы кызыл төстәге бишпочмак урнаштырылган; бишпочмак эчендә 90°ка сулга борып куелган алтынсу төстәге “К” хәрефеннән торган ике әйләнәле түгәрәк ныгытма сурәтләнгән ак түгәрәктән гыйбарәт. Түгәрәк алтынсу төстәге ике бәжра белән әйләндереп алынган, бәжралар арасында киңлеге Татарстан Республикасы Дәүләт флагындагы полосаларга пропорциональ булган яшел, ак һәм кызыл төсләрдәге бәжралар урнашкан.

Татарстан Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясенең
19.04. 2018 ел
№ 12-07/59

боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эмблемасының төсле рәсеме**



Кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы
көрәш бүлеге начальнигы ____________________________/Л.П. Василина/____________

Административ һәм суд практикасы
бүлеге
начальнигы урынбасары ________________________________/И.И. Җамалетдинов/_________